# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елдаТатарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

2024 елның 21 ноябрендәге
2 номерлы гражданнар җыены
карарына үзгәрешләр кертү турында

04.04.2025 ел № 12

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы, “2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 21 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү буенча 2025 елның 25 мартындагы 13 номерлы карары нигезендә

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы, “2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 21 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Бәзәкә авылында Бәзәкә елгасы аша күперләрне ремонтлау).

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( вак таш сатып алу, вак ташны тигезләү, Бәзәкә авылындагы юлларны кардан чистарту, узган елларның калган өлешләрен юлларны кардан чистартуга җибәрергә).

3. Урамнарны яктырту җайланмасы (Бәзәкә авылында яктырткычлар сатып алу). Бәзәкә авылында урамнарны яктырту җайланмасы урнаштыру).

4. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бәзәкә авылында Беларус 82.1 тракторына фронталь төягеч сатып алу, Беларус 82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу, техник хезмәт күрсәтү), бензин триммерлары сатып алу, үлән чабу, агачлар кисү, территорияне төзекләндерү өчен экскаватор хезмәтләре күрсәтү, балалар спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү).

5. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын буяу өчен буяу сатып алу).

6. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (суга батыру насослары сатып алу).

7. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Бәзәкә авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча хезмәт күрсәтүләр)

2. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә Бәзәкә авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы ______ И.И. Кәшәфетдинов
имза имзаны киңәйтү